# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

## "Халыклар дуслыгы" фестивале



16 нчы декабрь көнне мәктәптә традицион чара узды. Бу - "Халыклар дуслыгы" фестивале. Чарада 24 сыйныф катнашты, бу 6,7,8 һәм 10 сыйныф укучылары. Мәктәп традицияләренә карап, классларны Россия төбәкләре тәкъдим иткәннәр. Чарада укучылар гына түгел, педагоглар һәм ата-аналар да катнашты. Быел фестиваль кысаларында Россия халыкларының көнкүреш макетлары тәкъдим ителде.
Номерлар якты, кызыклы һәм үзенчәлекле булды. Билгеләнгән илнең үзенчәлелеген һәм матурлыгын тәкъдим итү өчен җитди әзерлек эшләре кирәк иде: балалар һәм сыйныф җитәкчеләре төбәкнең костюмын өйрәнергә, җыр-биюнең үзенчәләлекләрен күрсәтергә, танылган кешеләре турында сөйләргә тиеш иде. Һәр катнашучы сыйныф укучылары матур презентация әзерләгән, барысы да куелган максатларына иреште.

Фестиваль милли традицияләрне саклау һәм үстерү, халыкларның бердәмлеге һәм дуслыгы идеяләрен популярлаштыру максатында уздырылды. Чара бик эчтәлекле узды, укучыларның, педагогларның һәм ата-аналарның хәтерендә тирән эз калдырды.

Шуны да әйтеп узарга кирәк, "Халыклар дуслыгы" фестивале "ТР милли традицияләре һәм мәдәниятләре" елын тәмамлау кысаларында иң тирән эчтәлекле чараларның берсе булып тора.

## Рус теленнән йомгаклау иншасы

6 нчы декабрь көнне 11нче сыйныф укучылары рус теленнән йомгаклау иншасы яздылар. 3 сәгать 55 минут эчендә укучылар үзләренең әсәрләрендә түбәндәге бүлекләрдән торган теманы ачарга тиеш иде: “Кеше тормышында рухи-әхлакый юнәлешләр”; “Кеше тормышында гаилә, җәмгыять, ватан төшенчәсе”, “Кеше тормышында табигать һәм мәдәния”. Иншаны барысы да яхшы язганнар. Афәрин!

## 3 декабрь- Халыкара инвалидлар көне

Өченче декабрьдә барыбыз өчен дә әһәмиятле көн - язмыш сынауларына бирешмичә, тормышта үз урыннарын тапкан һәм аны чын күңелдән яраткан көчле рухлы, максатчан кешеләребез – Халыкара инвалидлар көне билгеләп үтелә. Сәламәтлекләре чикле булуга карамастан, күпләребез алардан нык, чыдам булырга, иң мөһиме - тормышны яратырга өйрәнә ала. Алар һәр мизгелнең кадерен тоя, һәр көнне шатланып каршы ала беләләр. Күпләре язмыш сынауларына баш имичә, ныклы ихтыяр көче, түземлек, сабырлык, тырышлык аша авырлыкларны җиңеп чыкканнар. Безнең көчле рухлы кешеләребез республика һәм федераль конкурсларда, фестивальләрдә катнаша, спорт ярышларында югары нәтиҗәләргә ирешә, төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә үзләренең иҗади эшләрен тәкъдим итеп, җиңүчеләр һәм призерлар булып тора. Без алар белән бергәләп, әлеге казанышлары һәм җиңүләре өчен горурланабыз һәм шатланабыз.
Инвалидлар - дөньяның нечкәлекләрен күрә белүче, эчке дөньясы бай кешеләр. Аларның кайберләре хәрәкәттә чикләнгән, кайберләре сөйләшү һәм ишетүдән мәхрүм кешеләр. Ләкин инвалидлар арасында талантлы язучылар, рәссамнар, җырчылар, биючеләр, спортчылар шактый күп. Шуларның берсе- Фәнис Яруллин. Аның шигырь юлларын язып үтәсебез килә.

Яши-яши шуны белдем,–
Тормыш мәңге сыный икән.
Намусына тугры кеше
Сынауларда сынмый икән.

Бу кешеләргә карата кайгырту, ярдәм итү, мәрхәмәт хисе безнең барыбызда да булсын иде. Аларга нык ихтыяр көче, яшәү теләге, өметле киләчәк теләп калабыз.

Гөмәрова Риана, 6нчы сыйныф укучысы

## 5 нче декабрь волонтерлар көне



Автономная некоммерческая организация
«Центр защиты семьи, материнства и детства «Умиление»



БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

Весь коллектив АНО «Центр защиты семьи, материнства и детства «Умиление» выражает сердечную благодарность учителям, ученикам и родителям МБОУ «Многопрофильная школа № 181» Советского района г. Казани за предоставленные новогодние подарки и канцелярские товары для подопечных семей и мам с детьми, проживающих в социальном доме «Колыбель», который создан для поддержки беременных и матерей с детьми, оказавшихся в трудной жизненной ситуации.

Примите от наших подопечных семей искреннюю благодарность за доброе дело, отзывчивость и милосердие. Надеемся на дальнейшее сотрудничество, взаимопонимание и поддержку. От всей души желаем всем вам крепкого здоровья, благополучия и гармонии!

*"Благотворительная душа будет насыщена, и кто напояет других, тот и*

С уважением,
Белянкина Э.Р.

Президент АНО «Центр защиты материнства «Умиление»

Россия Президенты Владимир Путин билгеләп үткәнчә, шәфкатьлелек, миһербанлылык, авыр хәлдә калганнарга риясыз ярдәм итәргә омтылу — кеше күңелендәге иң асыл кыйммәтләр.

Русиядә 5 декабрьдә Волонтер көне билгеләнә - башкаларга ярдәм итүче кешеләр бәйрәме. РФ-да волонтерлыкның йөзләгән юнәлешләре бар: ятимнәргә, яшьләр йортларында торучыларга, йортсызларга, инвалидларга, ялгыз пенсионерларга, балалар йортлары карамагына алучыларга, хайваннарга һ.б.
2023 нче елдан волонтерлар бәйрәме дүшәмбе көненә туры килә.


Тарихка күз салыйк.
1985 нче елдан БМО Ассамблеясе җәмгыять тормышы өчен волонтерлар эшчәнлегенең әһәмиятенә игътибар итә. Ул рәсми статус ала һәм ел саен бәйрәмнәргә күп кенә илләр кушыла.

2017нче елда беренче тапкыр Россиядә тантаналы чаралар булып узды.
Бөтендөнья буенча хәйрия фондлары һәм оешмалар мохтаҗлар өчен акча җыюны оештыра һәм актуаль проблемаларга игътибар җәлеп итү өчен акцияләр һәм флешмоблар уздыра. Активистлар барлык бәхетсез кешеләрне волонтерлар сафына керергә һәм халыкның яхшы категорияләренең тормышын үзгәртергә чакыра. Илләрнең рәсми затлары тантаналы рәвештә чыгыш ясый, волонтерларның фидакәрсез хезмәтен һәм аларның җәмгыятьне үстерүгә өлешен билгеләп үтә.

Хәйрия эшендә мәктәбебез һәрвакыт актив катнаша. Казаныбызның "Имәнлек" урамында урнашкан «Умиление» исемендәге гаиләне, аналарны һәм балачакны яклау үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасына һәрдаим ярдәм итеп килә.
Бу оешма 2016 елның 7 июлендә рәсми рәвештә теркәлгән. Оешма авыр тормыш хәлендә калган балалы хатын-кызлар һәм йөкле хатыннар өчен ярдәм күрсәтә.
Мәктәбебез җитәкчеләре, укытучылары, әти-әниләр һәм укучылар хәйрия эшендә актив катнаша. Оешмадан һәр ел саен рәхмәт хатлары җиткерелә. Без дә үз исемебездән катнашучыларның һәрберсенә рәхмәт җиткерәсебез килә.

## Рәхмәт сезгә, укучылар!

Махсус хәрби операцияләрдә катнашучыларга ярдәм йөзеннән 11 нче А сыйныф укучылары беренче ярдәм күрсәтү өчен булган медицина кирәк-яраклары әзерләделәр һәм эшләрен һаман да дәвам итәләр. Укучылар эшкә бик җаваплы карыйлар. Алар тәнәфесләрдә, дәресләрдән соң җыелышып, хәйрия эшләрен эшлиләр. Белгәнебезчә, меңләгән кеше үз гомерендә бик күп яхшылыклар эшли, чит-ятка да ярдәм кулы суза һәм моның өчен бернәрсә дә сорамый. Моның белән ул үзенә канәгатьләнү ала, игелек кыла, кешелек җәмгыяте каршындагы бурычын үти. 11 нче А сыйныф укучылары турында да шушы ук сүзләрне әйтеп була. Укучыларыбызга бик зур рәхмәт, -диясебез килә.







ТИЗДӘН, БИК ТИЗДӘН ЯҢА ЕЛ КИЛЕП ҖИТӘЧӘК.... АНЫ ҺӘРКЕМ КӨТӘ. ЯҢА ЕЛ- УЛ МОГҖИЗА КӨТҮ. ӘЙДӘГЕЗ, ХЫЯЛГА ЧУМЫП АЛЫЙК ӘЛЕ....

## Кыш бабайга хат язабыз

Барысы да Яңа елны яратып, чыдамсызлык белән көтәләр. Мин дә бу бәйрәмне бик яратам һәм аңа кадәр көннәрне саныйм. Кайбер җирдә декабрьнең уртасыннан бирле кешеләр йортны бизи башлыйлар, чәчәк киеп, шулай итеп үзләренә һәм башка кешеләргә бәйрәм күңелен тудыралар. Күп кенә егетләр Кыш бабайга хат язалар, ул аларның хыялларын үтәчәк, аларга бүләкләр китерәчәк дип ышаналар. Мин, бөтен балалар кебек үк, Кыш бабайга һәм Яңа елга була торган гаҗәпләргә ышанам.

Балалар, Кыш бабайга хатларны тизрәк языгыз, теләкләрегез булсын, ышаныгыз һәм алар үтәлер!!!

## Яңа ел төнендә мин төш күрдем...

Бер тапкыр Яңа ел төнендә мин төшемдә Франциядә булдым. Анда - хыял дөньясы. Мин 4 йолдызлы кунакханәдә идем.

...31 декабрь көнне без, бергәләп, бәйрәмгә әзерләндек. Чыршыны бизәдек, костюмнар кидек. Сәгать 12 дә барыбыз да өстәл янына утырыштык... Аннары без бүләкләрне карый башладык. Кемгәдер тәм-том, кайберәүләргә - мәктәп кирәк-яраклары, кайберәүләргә – конфетлар эләкте. Бергәләп бәйрәм иткәннән соң, без йокларга яттык. Мин фейерверк тавышыннан уянып киттем, күземне ачсам, мин караватта ята идем. Ә барысы да төштә генә булган икән...

Хәмидуллина Гөлинә, 6 нчы "З" сыйныф укучысы

## Кадерле балалар, хөрмәтле укытучыларыбыз! Яңа ел белән сезне!

Яңа бәхет, зур уңышлар
Алып килсен Яңа ел.
Шатлык белән үтсен һәр көне,
Котлы булсын, Яңа ел!

Яңа еллар котлы булсын
Дөньялар тыныч торсын
Куаныч булып торсын,
Табыннар тулып торсын!



**Редакциянең адресы:**420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576 **Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары**:
Хәмидуллина Гөлинә, Гөмарова Риана, Сафина, Самира, Хәзиев Әмин, Пеструхина Юлия, Мөхәммәдинова Мәрьям, Петрочинина Диана